СОВЕТ МОРТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МОРТ АВЫЛЫ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ с. Морты КАРАР

№ 76 «13» января 2023г.

**2023 елда Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Морт авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «Морт авыл җирлеге» Уставы нигезендә, Алабуга муниципаль районы Морт авыл җирлеге советы

Карары:

1. 2023 елда яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары белән Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Морт авыл җирлегенең муниципаль органнарында һәм җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелмәскә мөмкин.

2. Әлеге карарның 1 пункты Алабуга муниципаль районының Морт авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләнгәндә кулланылмый.

3. Әлеге карарны «Яңа Кама» газетасында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук рәсми сайтта урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Рәисе Ф. Ф. Закиров